**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2016 ел, 30 декабрь № 1066

г. Казань

«Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Матди-техник тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесен төзү турында

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Янгынга каршы хезмәте турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2008 ел, 15 февраль, 79 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының Янгынга каршы хезмәте турындагы нигезләмәнең 4 нче пунктындагы 5 пунктчаны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының «Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Матди-техник тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесен (алга таба – Учреждение) төзү турындагы тәкъдимен кабул итәргә, Учреждениенең төп эшчәнлек максатлары итеп янгын сүндерү һәм коткару техникасының, оператив-хезмәт транспорты һәм махсус транспортның, янгынга каршы-техник коралландыруның, йөзү чаралары, элемтә чараларының даими техник әзер булуын тәэмин итүне, шулай ук Татарстан Республикасының Янгынга каршы хезмәте һәм Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы каршындагы Эзләү-коткару хезмәте бүлекчәләренең матди-техник тәэминатын оештыру һәм гамәлгә ашыруны билгеләргә.

2. Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына:

Учреждениене гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкарырга;

ике ай эчендә Учреждениенең уставын расларга һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында каралган кирәкле оештыру чараларын тормышка ашырырга.

3. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Учреждениенең штат саны 46 берәмлек тәшкил итә дип;

Учреждениене финанслар белән тәэмин итү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында «Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы» ведомствосы буенча әлеге максатларга күздә тотылган акча чикләрендә гамәлгә ашырыла дип.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\1066.doc